# «Әле һаман сызлый яралар»

**(Багышлана Шәрипов Марат Шамил улына Балтач районы Югары Шубан авылында яши)**

1979 елларда игълан ителмичә генә башланып киткән мәгънәсез Әфган сугышы күп кенә гаиләләргә олы хәсрәт китерде, япь-яшь ир-егетләрнең язмышларын үзгәртте. Безнең Шубан авылыннан  дүрт егет катнашкан. Алар барысы да тау-таш арасында, үзенчәлекле климат шартларында сугышның дәһшәтен, бөтен авырлыгын һәм газапларын, кайгы-хәсрәтләрен үз җилкәләрендә татыганнар.

Минем язасы килгән мәкаләм, минем бабамның энесе – Марат абыем турында. Марат абыем 1964 елда Балтач районының  иң гүзәл, урман-суларга бай булган, табигате белән таң калдырган Югары Шубан авылында гаиләдә 2 нче бала булып дөньяга килгән.

Ул укып-белем алып, киләчәккә планнар кора. 18 яше тулып 1 ай  үтәр-үтмәс аңа Армия сафларына чакыру кәгазе килә. Шулай итеп Марат абыем 1982 нче елның 1 нче апрелендә армиягә китә. Башта Чирчик  шәһәрендә хәрби өйрәнүдә була, аннары язмыш аны Әфганстанның Баграм шәһәренә илтә. Ул анда  танк полкында хезмәт итә.

Әнисе,туганнары борчылмасын дип ул: «Пешекче булып хезмәт итәм»- дип хатлар яза. «Ул минем күңелем тыныч булсын дип, шулай язган инде. Әни күңеле барыбер сизенә бит, үзебезгә сабырлык теләп, көн арты көннәрне санап үткәрдек.» - дип искә ала карт әбием.

Туктаусыз юлда булу, утлы табадай кызу көннәр, төрле яклап шартлаган бомбалар, әледән – әле хәрби хезмәттәшләрен югалту, яраланулар – әлеге вакыйгаларны Марат абыем бүген йөрәк әрнүләре белән искә ала. Гомумән, ул сугыш турында әллә ни җәелеп сөйләргә яратмый, әллә нигә бер сөйләгән вакытларында да күзләре яшь белән каплана. «Армия хезмәте тәмамланган солдатлар, саубуллашып шатлыктан самолетка йөгерәләр, ә без аларга кызыгып, кул болгап калабыз. Ә берничә минуттан  ул самолетның һавада шартлаган хәбәре килә. Бу вакытта кичергәннәрне сүз белән аңлатып булмый» - ди ул. Беләм, сугышта күргәннәре, снаряд-бомбалар шартлавы, исәпсез-хисапсыз кеше мәетләре... болар барысы да бүгенгедәй күз алдында торадыр. Ике елдан артык хезмәт иткәч 1984 елның июль аенда ул исән-сау авылга әйләнеп кайта.

Марат абыем төп йортта төпләнеп кала. Авыл малае булганга күрә техниканы якын итә, колхозга эшкә кереп тракторга утыра.

Авыл кибетенә эшкә килгән Сосна кызы Фәридә белән танышып матур гаилә корып җибәрәләр. Бер ул һәм бер кыз үстерәләр.

2002 елдан шәхси эшмәкәрлеккә күчә, Шубан авылында хуҗалыклардан сөт җыя башлый.

Марат абыем бик эшчән, тырыш кеше. Күп итеп маллар асрый, җир эшкәртеп үзенә кирәкле иген һәм печән үстерә. Аңа бу эшендә улы Рәис тә булыша. Минем өчен Марат абыем һәрвакыт үрнәк алырдай кеше.

Марат абыемның армиядәге вазыйфасы һәм хәрби исеме: сержант.

Ул «Сугышчы интернационалист» исемле күкрәк билгесе һәм «СССРның хәрби көчләренә 70 ел», «Изге Әфган сугышында катнашканы» өчен медальләре белән бүләкләнә.






Эшләде: Хәйруллин Кәрим
Булат улы (12 яшь)
МБГБУ «Балтач гимназиясе»
6 нчы сыйныф укучысы
Югары Шубан авылы